**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**АКСУБАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**КӘКРЕ КҮЛ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ.**

# КАРАР

4 номерлы 2020 елның 26 феврале

Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы
Кәкре Күл авыл җирлеге башкарма комитетының
«2015 елның 28 октябрендәге 13нче номерлы
«Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы
Кәкре Күл авыл җирлегенең коммуналь инфраструктура
системаларын комплекслы үстерү программасын
раслау турында»гы карарына үзгәрешләр кертү турында

Муниципаль берәмлекнең хокукый базасын Россия Федерациясе Бюджет кодексының 179 статьясы таләпләренә туры китерү, “Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында" 2019 елның 27 декабрендәге 104 - ФЗ номерлы Федераль закон редакциясендә, программа-максатчан планлаштыру тәртибен камилләштерү максатларында, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының «Кәкре Күл авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына нигезендә КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Кәкре Күл авыл җирлеге башкарма комитетының « Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Кәкре Күл авыл җирлегенең коммуналь инфраструктура системаларын комплекслы үстерү программасын раслау турында" 2015 елның 28 октябрендәге 13 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Карарның исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә: " «2015-2024 елларга Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Кәкре Күл авыл җирлегенең коммуналь инфраструктурасы системаларын комплекслы үстерү»муниципаль программасын раслау турында"..

1.2. Программа тексты буенча "муниципаль максатчан программа" сүзләрен "муниципаль программа" сүзләренә алмаштырырга, тиешле килештә һәм санда.

2. Программага кушымта итеп бирелә торган редакция нигезендә кушымтаны бәян итеп, чаралар юнәлешләре буенча финанслау күләмнәрен бүлү өлешендә үзгәрешләр кертергә.
3. Әлеге карарны Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга: http://Aksubayevo.tatarstan.ruһәмхокукый мәгълүматның рәсми порталында бастырып чыгарырга:http://pravo.tatarstan.ru/
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Аксубай муниципаль районы
Кәкре Күл авыл җирлеге
башкарма комитеты җитәкчесе С.С. Елисеев

Программага кушымта.

«2015-2024 елларга Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Кәкре Күл авыл җирлегенең коммуналь инфраструктурасы системаларын комплексы үстерү»муниципаль программасын раслау турында''.

| № т/б | Чаралар | Еллар буенча чаралар үтәлеше | | | | | Искәрмә |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | 2020 | 2021 | 2022 | 2023 | 2024 | |
| 1 | Кәкре Күл, Түбән Баланда, Югары Баланда авылларында су белән тәэмин итү системаларын карап тоту һәм хезмәт күрсәтү | 3 суэтем башнясы 25 км сууткәргеч 350000 сум. | 3 суэтем башнясы 25 км сууткәргеч 350000 сум. | 3 суэтем башнясы 25 км сууткәргеч 355000 сум. | 3 суэтем башнясы 25 км сууткәргеч 360000 сум. | 3 суэтем башнясы 25 км сууткәргеч 365000 сум. | Финанслау күләме. Программа прогнозланган характерда һәм тиешле елга тиешле дәрәҗәләрдәге бюджетларны формалаштыруны, шулай ук чараларны финанслашуга республика һәм район бюджетыннан акча бүлеп бирүне исәпкә алып, ел саен төзәтмәләр кертергә тиеш. |
| | Барлыгы | 350000 | 350000 | 355000 | 360000 | 365000 | |